СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-60, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**15 август, 2024 ел** **№ 428**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 30 мартындагы 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы прокуратурасының гамәлдәге муниципаль норматив хокукый базага үзгәрешләр кертүне таләп итә торган федераль законнарга үзгәрешләр турындагы мәгълүматы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 30 мартындагы 127 номерлы карары (22.05.2020 № 373, 15.09.2021 № 104 карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 пунктның б пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Россия Федерациясе Президенты билгеләгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография беркетеп;»;

1.2. 14 пунктның з пунктчасында «медицина учреждениесе» сүзләрен «медицина оешмасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә һәм Интернет мәгълүмат -

телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамөтдинов